**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл жирлеге Чәкән торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**26 ноябрь 2020 ел** **№2**

2003 елнын 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда 1 теркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иту буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Чәкән торак пунктының Яңа урам буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау);

-Чәкән торак пунктында православие һәм мөселман зиратларында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләп алу очен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, киртәләр урнаштыру);

- Чәкән торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен отвал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Чәкән торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, лампаларны, яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган һәйкәлне реконструкцияләү (килешү буенча эшләр ечен түләү);

- Чәкән авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көнө», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көнө», «Яңа өл» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: И.Б. Бохарова